УПРАВЛЕНИЕ ЗАГС
КАБИНЕТА МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Ахтямова, дом 14,
город Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ
ГХАТ ИДАРӘСЕ
Әхтәмов урамы, 14 нче йорт,
Казан шәһәре, 420021

Тел./ факс: (843) 293-14-89, zags@tatar.ru, zags.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**Казан ш.**

______20.02________ **2023 ел** **№ _10___**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең 2018 елның 13 сентябрендәге 66 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2018 елның 13 сентябрендәге 66 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.2 пунктында «проект актын сайтта» сүзләреннән соң «һәм Мәгълүмат ресурсында» сүзләрен өстәргә.

4 нче бүлекнең 4.4 һәм 4.5 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.4. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Идарәгә алынган бәяләмә (алга таба – бәяләмә) килгән көненнән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документ әйләнеше буенча бердәм ведомствоара системасында теркәлә һәм актны (акт проектын)

әзерләү өчен җаваплы булган Идарәнең структур бүлекчәсенә карау өчен җибәрелә.

4.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә киңәш итү холкына ия һәм, әлеге пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән очраклардан тыш, теркәлгән көненнән башлап 15 көнлек срокта Идарә тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

Карау нәтиҗәләре буенча коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка нигезләнгән җавап (бәяләмәдә ачыкланган коррупция факторлары турында мәгълүмат яки ачыкланган коррупция факторларын бетерү ысулы турында тәкъдим булмаган очраклардан тыш) җибәрелә, анда коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләренең исәпкә алынуы һәм (яки) актта яки акт проектында ачыкланган коррупция факторы белән риза булмау сәбәпләре чагылдырыла.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәге бәяләмәләр каралырга тиеш түгел:

актларга һәм актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру буенча экспертлар сыйфатында Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында аккредитацияләнмәгән юридик затлар һәм физик затлар тарафыннан әзерләнгән;

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы раслаган формага туры килми торган.

Әлеге пунктның бишенче абзацында күрсәтелгән очракта, Идарә мондый бәяләмәне, сәбәпләрен күрсәтеп, теркәлү көненнән соң 15 көннән дә соңга калмыйча кире кайтара.»;

4 нче бүлекнең 4.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу әлеге Тәртипнең 4.5 пункты нигезендә башкарыла»;

4 нче бүлекнең 4 нче пунктында «Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе указлары проектларында» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче бүлекнең 5.3 нче пунктының дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәсендә» сүзләренә алмаштырырга.

Идарә җитәкчесе Г.Р.Нигъмәтуллина

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ГХАТ идарәсе боерыгына килештерү кәгазе**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсендә норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»

________________№___________

| Тәртип саны | Вазыйфа | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Имза | Дата | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| **КИЛЕШТЕРЕЛДЕ** | | | | | |
| 1. | Идарә җитәкчесе урынбасары | Р.Х.Әхмәтҗанов | | | |
| **ӘЗЕРЛӘНДЕ** | | | | | |
| 2. | Хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе | Л.Ф.Мортазина | | | |

Өстәмә эшләп
бетерүгә тапшырылды ________________________________________
(дата, кемнән)

Имзалау өчен тапшырылды

___________________________________________________
(дата, эшне алып бару өчен җаваплы хезмәткәрнең визасы)